РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ СТАРОБАЙСАРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423745, село Старое Байсарово,
ул. Школьная,дом 44а,
Тел. 3-44-53
Email: bay.akt@yandex.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ БАЙСАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

423745, Иске Байсар авылы,
Мәктәп ур., 44а йорт. Тел.3-44-53
Email: bay.akt@yandex.ru


**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«12» апрель 2023 ел № 6

## Җирле салымнар суммасы буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләр билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Иске Байсар авыл җирлеге Уставы нигезендәТатарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, варисларның берсе дә мирас алырга хокуклы түгел яки барлык варислар да мирас алудан читләштерелгән, яки варисларның берсе дә мирасны кабул итмәгән, яки барлык варислар мирастан баш тарткан һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәгән;

2) салым түләүченең гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы;

3) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы;

4) җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы.

2. ТР Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлеге Советының 11.01.2023 елгы 2 номерлы карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Иске Байсар авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Иске Байсар авыл җирлеге башлыгы Р.М.Кадыйровка йөкләргә.

Совет рәисе, авыл җирлеге башлыгы: Р.М.Кадыйров